
Хуш киләсең, Чаллы театры! / Р. Хафизов [б-н әңгәмә] // Сәхнә. – 2023. – №2 (206). – Б. 6-8.

# ХУШ КИЛӘСЕҢ,
## ЧАЛЛЫ ТЕАТРЫ



А. Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театры башкалабыз тамашачысын Казан гастрольләренә чакыра. 14-16 февраль көннәрендә Г. Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театрының зур залында Чаллы театры Ф. Бурнашның «Яшь йөрәкләр», А. Әхмәтгалиеваның «Капка» һәм А. Гыйләҗевнең «Болан» спектакльләрен тәкъдим итәчәк. Казан тамашачысына күрсәтеләчәк спектакльләр һәм Чаллы театрының бүгенгесе хакында «Сәхнә» журналына Чаллы татар дәүләт драма театрының башкарма директоры Хафизов Рәсим Рәхимҗан улы сөйләде.





— Бу безнең Камал театрының зур сәхнәсенә беренче тапкыр килүебез. Ни өчен дигәндә, без әле яңа бинага 2 ел элек кенә күчендек, элеккеге бинада сәхнәбез кечкенә иде. Шуңа күрә анда куелган спектакльләрне зур форматлы сәхнәгә алып килә алмый идек. Ә хәзер безнең андый мөмкинлек бар, без искиткеч яңа бинада, зур сәхнәдә иҗат итәбез. Монда күченеп килгәннән бирле яңа сәнгать җитәкчебез Олег Кинҗәгулов яңа репертуар планы туплау белән шөгыльләнде. Кызганыч, күп кенә спектакльләр яңа сәхнәгә туры килмәде, чөнки зур сәхнәдә алар югалып кала. Шушы вакыт эчендә яңадан-яңа спектакльләр туды, инде без үзебез дә Камал театрының данлыклы сәхнәсендә чыгыш ясау дәрәҗәсенә җиттек сыман. Бер яктан бу безнең театрыбыз өчен зур сынау, икенче яктан, спектакльләребезне, артистларыбызны, эшебезне Казан тамашачысына күрсәтү мөмкинлеге.


Казан гастрольләренә театрыбызның иң «кассовый» спектакльләрен сайлап алдык. Бер комедия һәм ике драма. Театрыбыз репертуарында комедияләр бик күп, шулай да бу юлы тирән мәгънәле, уйландыра торган спектакльләр алып киләсе килде. Без иҗади яктан үсәбез,



Фотолар А. Гыйләҗев исемендәге Чаллы татар дәүләт драма театрының матбугат үзәгеннән алынды.



SCAN AnyScanner



яңа урләр яулыйбыз, безнең белән бергәлектә тамашачы зәвыгы да үсә, үзгәрә. Төп максатыбыз — тамашачыны уйланырга этәрү. Гастрольләребез репертуары да шушы максатны күз алдында тотып сайланды. Казан тамашачысына 14 февральдә Ф. Бурнашның «Яшь йөрәкләр» музыкаль комедиясе, 15 февральдә А. Әхмәтгалиеваның «Капка» спектакле һәм 16 февральдә А. Гыйләҗевнең «Баласын җуйган болан эзеннән» әсәре буенча куелган «Болан» спектакльләрен тәкъдим итәбез. Бу спектакльләргә килгән тамашачы геройларда үзен күрә, тамашадан соң килеп үз фикерләрен белдерә, кичерешләре белән уртаклаша. Шуңа күрә Казан сәхнәсе өчен нәкъ менә әлеге спектакльләр сайланды. Хөрмәтле Казан тамашачысын үзебезнең спектакльләребездә көтеп калабыз.

**—Рәсим Рәхимҗанович, сезнең театр сәнгатенә килеп керүегез ничек булды? Моңарчы эшчәнлегегез сәнгать белән бәйле идеме?**

—Һөнәрем буенча мин татар теле һәм әдәбияты укытучысы. Институтта укыганда күп төрле бәйгеләрдә катнашып, актив студент булуымны күреп, уку йортын тәмамлаганда ректорыбыз Фәйрүзә Зөфәровна Мостафина театрга барырга киңәш итте. Ул вакытта Фәйрүзә апа мине артист буларак театр сәнгатендә күрергә теләгән, күрәсең. Шул вакытта мин мәктәпне сайладым, анда да һәркемнең үз роле, һәр көн 30 тамашачым каршында чыгыш ясадым. 6 ел укытучы, сыйныф җитәкчесе, 1 ел тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып эшләдем. Балалар белән эшләүне, укытучы эшчәнлеген билгеле бер дәрәҗәдә сәнгать белән бәйле дияргә була. Ләкин күпмедер вакыт үткәч, тормыш мине барыбер театр дөньясына алып килде.

**—Чаллыда театрлы халык яшиме? Казан театрлары белән чагыштырганда, биредә театр сәнгатенең кыйммәте нинди дәрәҗәдә? Читтән караганда Чаллы — сәнгатьтән ерак, сәнәгать шәһәре кебек тоела...**


—Мондый фикерне ишетү кызыклы, тик аның белән килешәсе килми. Чаллы автомобильләр җитештерү шәһәре



булса да, 2 ел эчендә шәһәребездә 2 әр-яңа театр бинасы барлыкка килде. «Мастеровые» рус драма театры һәм безнең А. Гыйләҗев исемендәге татар дәүләт драма театры яңа биналы булды. Бу бит бездәге сәнгать дәрәҗәсенең күрсәткече, димәк, бездә дә сәнгать турында уйлыйлар дигән сүз. Ә тамашачыларга килгәндә, театрыбызга йөрүчеләр елдан-ел күбәя, Аллаһка шөкер. Хәтта рус тамашачысының саны да артты. Спектакльне тәрҗемә белән карау күбрәк милли театрларга хас күренеш. Колакчыннарны алучылар саныннан чыгып без татар театрының башка милләт вәкилләре өчен дә кызыклы булуын күреп сөенәбез.

**— Бүгенге тамашачы таләпчәнме?**

— Соңгы елларда тамашачының зәвыгы үзгәрде, хәзер алар театр белән диалогка керергә курыкмый. Берәүләре спектакль беткәч фикерен әйтеп китә, икенчеләре социаль челтәрләрдә кайтавазын белдерә. Бүгенге көндә үзенә ошамаган, спектакльнең җитешмәгән яклары турында турысын бәреп әйтә белә торган тамашачылар катламы барлыкка килде. Сәхнәдә әз генә затсызрак сүз ишетелсә дә, шундук шелтә килеп ирешә. Тамашачы хәзер бөтен әйбергә игътибар итә, димәк кызыксына. Алар тарафыннан шушындый кайтавазлар ишетү безнең өчен бик кыйммәтле. Халык сәнгатькә йөз белән борылды. Хәзер тамаша залында киемен култык астына кыстырып кергән, баш киемен салмаган тамашачы юк, алар бирегә иң затлы



киемнәрен киеп, бәйрәмгә килгән кебек йөриләр.

Театр һәрвакыт тамашачыга ачык булырга тиеш. Ул иртәдән кичкә кадәр эшләргә тиеш. Без шушы максатны үз алдыбызга куеп эшлибез. Театрыбызның яңа бинасында коворкинг үзәге бар, без аны театрның «Яшьләр каурые» дип атыйбыз. Биредә яшьләр белән күп кенә чаралар уза. Шушындый очрашулар аша да без яшьләрне театр дөньясына якынайтабыз. Театрыбызның икенче катында күргәзмәләр залы эшләп килә, биредә төрле тематикаларга күргәзмәләр оештырыла. Шул рәвешле спектакль карарга килгән тамашачы матур сәнгать үрнәкләре белән дә таныша ала. Менә шундый матур, зур театр бинасында яраткан тамашачыларыбыз белән бергәләп тормыш күрәбез.







■ ■ ■